КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 16 апрель г.Казань № 232

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 16 гыйнвар, 15 нче карары белән расланган Индустриаль (сәнәгать) парклар, сәнәгать технопарклары, югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар төзү, аларның мәйданын арттыру яки аларны реиндустриализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен хосусый милек рәвешендәге индустриаль (сәнәгать) паркларның, сәнәгать технопаркларының, югары технологияләр өлкәсендәге техно-паркларның идарәче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индустриаль (сәнәгать) парклар, сәнәгать технопарклары, югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар төзү, аларның мәйданын арттыру яки аларны реиндустриализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен хосусый милек рәвешендәге индустриаль (сәнәгать) паркларның, сәнәгать технопаркларының, югары технологияләр өлкәсендәге техно-паркларның идарәче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 16 гыйнвар, 15 нче карары белән расланган Индустриаль (сәнәгать) парклар, сәнәгать технопарклары, югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар төзү, аларның мәйданын арттыру яки аларны реиндустриализацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен хосусый милек рәвешендәге индустриаль (сәнәгать) паркларның,

сәнәгать технопаркларының, югары технологияләр өлкәсендәге техно-паркларның идарәче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«идарәче компаниянең әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән таләпкә туры килүе Россия Федерациясе Бюджет кодексының 241 статьясындагы 15 пункты нигезләмәләрен субсидияләргә һәм Россия юридик затларына бирелә торган бюджет инвестицияләренә карата кулланылмау турында (Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан күрсәтелгән кагыйдәләр кабул ителгән очракта) карарлар кабул итү кагыйдәләрен билгели торган норматив хокукый актлар нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнә.»;

3.1 пунктның «б» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Идарәче компания Министрлыкка әлеге пунктчаның ундүртенче абзацында күрсәтелгән документларны электрон образ рәвешендә тапшырырга хокуклы.»;

4.4 пунктның дүртенче абзацында «биш эш көне» сүзләрен «50 эш көне» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2025 елның 16 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин